СОВЕТ МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

11.01.2016 с. Русское Макулово 7-40

Макыл авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Макыл авыл җирлеге Уставының 11 ст., «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2015 елның 16 декабрендәге 6-36 номерлы Макыл авыл җирлеге Советы карары, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2015 елның 16 декабрендәге 10 номерлы Макыл авыл җирлеге башлыгы карары нигезендә

Югары Ослан муниципаль районының
акыл авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2016 елның 6 мартына Макыл авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«2016 елда авыл җирлегенең җирле референдумда катнашу хокукына ия һәр кешесеннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән килешәсезме:

- Макыл авыл җирлеге территориясендә урнашкан су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау һәм реконструкцияләү гомуми суммасы 664500 сум: 840 метр озынлыктагы су скважиналарын киртәләү, автомат җайланмаларны урнаштыру - 4 шт, насосларны алыштыру - 7 данә, су суырту скважиналарын буяу - 6 данә, 300 метр озынлыктагы су асты электрүткәргечен алыштыру, су суырту башняларын ныгытуны 18 данә алыштыру, 150 метр озынлыктагы торбаны өлешчә алмаштыру.

ӘЙЕ ЮК".

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка чыгарырга, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге башлыгы                    А. И. Матвеева